**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**26.09.2023** № 607

**«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына агросәнәгать комплексына ярдәм чаралары турында " Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 04.08.2021 № 505 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә ярдәм итү максатларында, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Тәтеш муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына агросәнәгать комплексына ярдәм чаралары турында»04.08.2021 № 505 Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган сөт юнәлешендәге мини-ферма төзү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертергә Татарстан Республикасы":

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөт юнәлешендәге мини-фермалар төзү чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенең 5 пункты:

Субсидия шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданга бер тапкыр подряд ысулы белән яки шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның үз көче белән башкарылган мини-ферма төзелеше белән бәйле чыгымнарның бер өлешен 150 000,00 (йөз илле мең сум) күләмендә бер объектка һәм бер шәхси ярдәмче хуҗалыкка кайтаруга бирелә.

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Ф. Әхмәтшинга йөкләргә.

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**